**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Илюткино авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАРЫ**

«04» апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Илюткино авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. Алдан расланган гражданнар җыенында чыгарылган сорауларга үзгәрешләр кертү:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Илюткино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 18 октябрендәге 1 номерлы карары

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Илюткино авылында гражданнар Җыенының 18.10.2023 ел, № 2 карарын аны түбәндәге редакциядә раслап:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлегенең Илюткино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан тыш 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Илюткино авылындагы торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын салу, ремонтлау, карап тоту;

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен ремонтлау;

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт территориясен төзекләндерү.

Халык җыенында рәислек итүче: А.М.Шакирова

Би Күле авыл җирлеге башлыгы А.М.Шакирова